МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.11.2018 Казан ш. № 541

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2018 елның 17 маендагы 226 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында бертип нигезләмәгә үзгәреш кертелүгә бәйле рәвештә, **боерык бирәм:**

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2018 елның 17 маендагы 226 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

5.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.12. Иҗтимагый совет карары нигезендә, Иҗтимагый совет утырышларына Иҗтимагый совет тарафыннан каралучы мәсьәләләр буенча кирәкле белешмәләрне һәм бәяләмәләрне бирү өчен башкарма органнарның, коммерциячел булмаган оешмаларның, фәнни учреждениеләрнең вәкилләре, экспертлар, башка белгечләр һәм гражданнар чакырылырга мөмкин.

Иҗтимагый совет әгъзалары булып саналмаган массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре Иҗтимагый совет чакыруы буенча Иҗтимагый совет утырышларында катнашырга мөмкин. Иҗтимагый совет үз эшендә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзаларының катнашуын тәэмин итә.».

**Министр** **Ф.С Габделганиев**